РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Ш. Марджани, дом 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш. Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

«25» 02 **2026 ел** № 31

Әтнә муниципаль районы Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Әтнә муниципаль районының бюджеты» турындагы 2025 елның 12 декабрендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр керту хакында

Әтнә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.И. Гыймадиев докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. Әтнә муниципаль район Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Әтнә муниципаль районының бюджеты» турындагы 2025 елның 12 декабрендәге 14 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. 2026 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

а) Әтнә муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 876092,1 мең сум;

б) Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 890794,0 мең сум;

в) Әтнә муниципаль районының бюджет дефициты 14701,9 мең сум»

2) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 1 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

3) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 2 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

4) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 3 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 3 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

5) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 4 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 4 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

6) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 5 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 5 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

7) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 9 нчы кушымтаның 1 нче таблицасын 9 нчы кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әтнә районы башкарма комитетының «Өстәмә акча бүлеп бирү турында»гы карарларын расларга: №47, 27.01.2026; №57, 11.02.2026; №58, 12.02.2026; №63, 17.02.2026; №70, 24.02.2026.

3. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы www.pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Р.Ш. Хисамиев